ГОСУДАРСТВЕННАЯ
ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Б.Красная, 15/9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ДӘҮЛӘТ
ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ

Б.Красная ур. 15/9, Казан шђџђре, 420111

тел/факс. 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ _26_

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

«_2_» _март_ 2023 ел.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең «Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү турында» 2018 елның 23 августындагы 322 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең норматив хокукый актын Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең «Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү турында» 2018 елның 23 августындагы 322 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3 бүлек. ТР ДТИ актлары проектларына, шулай ук ТР ДТИ тарафыннан эшләнә торган Россия Федерациясе актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза

3.1. ТР ДТИ актлары проектларына, шулай ук эшләнә торган актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза аларның хокукый экспертизасын үткәрү белән бер үк вакытта үткәрелә.

3.2. ТР ДТИ актлары проектлары һәм эшләнә торган актлар проектлары проектны эшләү өчен җаваплы булган ТР ДТИ структур бүлекчәсе җитәкчесе тарафыннан  җаваплы затка (ТР ДТИ хокук идарәсе юридик бүлеге җитәкчесенә) коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен җибәрелә.

3.3. Алынган ТР ДТИ актлары проектлары һәм эшләнә торган актлар проектлары (алга таба – проектлар) җаваплы зат тарафыннан кергән көнне журналга теркәлә. Коррупциягә каршы экспертиза проект теркәлгәннән соң ун көн эчендә үткәрелә.

3.4. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре җаваплы зат тарафыннан әлеге Тәртипнең 1.4 пункты нигезендә төзелгән бәяләмә белән рәсмиләштерелә һәм журналда чагылдырыла. Бәяләмә төзелгән көнне проектны җибәргән структур бүлекчәгә тапшырыла.

3.5. Коррупция факторлары булганда, проектны әзерләгән структур бүлекчә өч көн эчендә проектны эшләп бетерә һәм аны җаваплы затка кабат коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен җибәрә. Коррупциягә каршы кабат экспертиза өч көн эчендә үткәрелә.

3.6. Эшләп бетерелгән проектта коррупция факторлары булмаса, җаваплы зат тиешле бәяләмәне проектны кабат коррупциягә каршы экспертизага җибәргән структур бүлекчәгә җибәрә.»;

4.3 пунктта «җыелма анализ һәм автоматлаштыру бүлеге» сүзләрен «аналитика һәм контроль секторы» сүзләре белән алыштырырга;

4.6 пунктта «кабул ителгән көннән алып 30 көн эчендә» дигән сүзләрне «теркәлгән көннән алып 15 көн эчендә» сүзләре белән алыштырырга;

4.10 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләре белән алыштырырга.

2. Юридик бүлек җитәкчесенә әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

Җитәкче С.А. Крайнов